РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА АДАВ-
ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» апрель 2016ел № 4

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында»

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2015елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар имза салынган вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районының Адав-Толымбай
авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Хөсниева

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан
вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына
китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну
барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында
нигезләмә

1.Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлегендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2.Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезендә хәбәр итәргә, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чараларын күрергә тиеш.

Хәбәр вазифаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр рәвешендә язма рәвештә рәсмиләштерелә (алга таба - хәбәрнамә).

3. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүчеләр 1 нче кушымтада каралган рәвеш буенча төзелгән авыл җирлеге башлыгына хәбәр җибәрә.

4. Авыл җирлеге башлыгы Буа муниципаль районы Башлыгына 2 нче кушымта нигезендә форма буенча төзелгән хәбәрнамәне җибәрә.

5. Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы, Буа муниципаль районы Башлыгы адресына кергән мөрәҗәгатьләр карау өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба - Комиссия) тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия хәбәрнамәләр җибәргән затлардан аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрергә хокуклы.

6. Хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән нәтиҗә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар Комиссия утырышына тапшырыла, ул Комиссиягә хәбәрнамә кергән көннән алып җиде эш көне эчендә уздырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гарызнамәләр, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар җибәрелгән

очракта, Буа муниципаль районы башлыгы Адав-Толымбай авыл җирлеге хәбәрнамәләре кабул ителгән көннән алып 45 көн эчендә, күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел.

7. Комиссия Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2014елның 16 декабрендәге 5-43номерлы номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында нигезләмәләр хакында» карары белән расланган (Советның 2014 елның 13 февралендәге 12-45 номерлы, 2014 елның 14 августындагы 10-50 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Комиссия турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәләрне карый һәм алар буенча карарлар кабул итә һәм кабул ителгән карарны Буа муниципаль районы башлыгына җибәрә.

8. Буа муниципаль районы Башлыгы Комиссиянең хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликты булмавын танырга;

б) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан шәхси кызыксынучанлык мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары үтәлмәгәнлеген танырга.

9. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә Буа муниципаль районы башлыгы мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чараларын күрүне тәэмин итә йә хәбәрнамә юллаган затка шундый чаралар күрергә тәкъдим итә.

10. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Буа муниципаль районы башлыгы Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын күрә.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан
вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына
китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну
барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында
нигезләмәгә 1 нче кушымта

_________________________
(танышу турында тамга)

Авыл җирлеге башлыгына_________________________
_____ ________________
____________________________________
кемнән
__________________________________
(Ф.И.О.,вазыйфа)
____________________________________

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр:____________________________________________________
______________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: ______________________________________
______________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ___________________________________________________
______________________________________________________________________

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы ____________муниципаль районы мәнфәгатьләре конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (тиешле фикерен ассызыкларга).

«___»_______________ 20__ ел. ______________________
__________________________

(хәбәрнамә җибәрүче кешенең имзасы) (имзаны тутырып язу)

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан
вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына
китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну
барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында
нигезләмәгә 2 нче кушымта

___________________________
(танышу турында тамга)

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгына

(кемнән)_________________________________
(Ф.И.А.и..,вазыйфа)

______________________________________

_____________________________________

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә

Мин үземнең вазифа бурычларымны үтәгәндә Шәхси кызыксынуым барлыкка килүе турында хәбәр итәм, бу мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин (кирәклесен ассызыклап үтәргә кирәк).

Шәхси кызыксынуның барлыкка килүенә нигез булган шартлар: ________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Шәхси кызыксыну тәэсир иткән яки тәэсир итә алган эш бурычлары:______________________________________

_____________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителгән чаралар: ______________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Әлеге хәбәрнамәне караганда муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (кирәклесен сызырга).

«___»_______________ 20__ ел. _______________________

___________________________

(хәбәрнамә җибәрүче кешенең имзасы) (имзаны тутырып язу)